# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран торак пунктында
20254 елда үзара салым кертү турында

15 ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елнын 06 октябрендәгы № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Яхшы-Каран авылы территориясендә теркәлгән инвалидлардан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткәннәр) һәм көндезге уку формасы буенча укучы, хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәтләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Яхшы-Каран т.п. урамнарында яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы (лампа, энергияне сак тоту яктырткычлары, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

2) Яхшы-Каран авылында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3) Мифтахов урамы буенча вак таш өслек ремонтлауны, (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүне);

4) Яхши-Каран поселогында һәйкәлләрне ремонтлау һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү ( ремонт, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны Александровка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында ( http:// sarmanovo. tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге башлыгы
гражданнар җыенында рәислек итүче И.Ф.Вафин